ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » декабрь 2025 ел № 1272

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында 2022 елның 28 февралендәге 175нче нмоерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәреш кертү турында” 2025 елның 29 сентябрендәге 776нчы номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтага ярашлы рәвештә җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын расларга.

2. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турына” 2025 елның 14 апрелендәге 338нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И.Г.Сираҗиевка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
“24” 12. 2025 ел, № 1272
кушымта

# Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты (алга таба – Регламент) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

2. Хезмәтне алучылар: физик (шул исәптән шәхси эшмәкәрләр) һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

3. Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш.

## II. Хезмәт күрсәтү стандарты

### Хезмәт исеме

4. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү.

### Хезмәт күрсәтүче орган исеме

5. Хезмәтне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) күрсәтә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче бүлекчә – Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы.

### Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче “Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне” сорап мөрәҗәгать иткәндә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып тора:

1) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар (5 нче кушымта);

2) хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (6 нчы кушымта).

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

7. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Башкарма комитет вазыйфаи затының (яки Башкарма комитетның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮдә Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин.

9. Мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында электрон документ яисә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

## Хезмәт күрсәтү вакыты

10. Республика порталы аша Башкарма комитетка, КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) карамастан, хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 30 эш көне тәшкил итә.

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен билгеләнгән тәртиптә шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү белән кызыксынган физик яисә юридик зат инициативасы буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырганнан соң шәһәр төзелеше регламентына кертелгән очракта хезмәт күрсәтү вакыты – тугыз эш көне.

11. Хезмәт күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән соң икенче көнгә исәпләнә башлый.

Электрон документ рәвешендә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитетта һәм КФҮдә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

## Хезмәт күрсәтү вакыты

12. Республика порталы аша Башкарма комитетка, КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) карамастан, хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 30 эш көне тәшкил итә.

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен билгеләнгән тәртиптә шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү белән кызыксынган физик яисә юридик зат инициативасы буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырганнан соң шәһәр төзелеше регламентына кертелгән очракта хезмәт күрсәтү вакыты – тугыз эш көне.

13. Хезмәт күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән соң икенче көнгә исәпләнә башлый.

Электрон документ рәвешендә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитетта һәм КФҮдә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

14. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны башкарма комитет түбәндәге нигезләр булганда кабул итә:

1) Регламентның 3 нче кушымтасында билгеләнгән документларны тапшырмау;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турындагы белешмәләрне расламау, гаризаның (гарызнамәнең) мөрәҗәгать итүче исеменнән аны бирүгә вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан бирелүе;

3) документларны тиешсез органга тапшыру;

4) дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр, килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген берсүзсез аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар булган документларны, үз көчен югалткан документларны тапшыру;

5) муниципаль хезмәтне Регламент нигезендә муниципаль хезмәтне алучы булып тормаган заттан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;

6) гаризаның электрон рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон рәвешендә һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу;

7) гаризада һәм аңа кушып бирелгән документларда каршылыклы белешмәләр булу;

8) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда текстны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар һәм төзәтүләр булуы.

15. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

16. Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) рөхсәт аңа карата дәүләт хакимиятенең башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан ирекле төзелешне ачыклау турында хәбәр алынган капиталь төзелеш объекты яисә җир кишәрлеге өчен файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә сорала;

2) дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарыннан файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә җир кишәрлегенең урнашуы турында мәгълүмат һәм файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән сорала торган төре әлеге зоналар чикләрендәге чикләүләргә каршы килә;

3) гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек берләшмәсенә бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән аерым бакча яисә яшелчә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү;

4) файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүдән баш тарту турында, шул исәптән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча тискәре бәяләмәне исәпкә алып, комиссия тәкъдимнәре;

5) файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә сорала торган рөхсәт техник регламентлар, шәһәр төзелеше, төзелеш, санитар-эпидемиологик, янгынга каршы һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нормалар һәм кагыйдәләр таләпләрен бозуга китерә;

6) мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча хезмәт күрсәтүгә гаризаның кире алынуы.

17. Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

### Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

18. Хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

### Хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

19. Хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артмаска тиеш.

20. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

### Мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәсен теркәү вакыты

21. КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирелгән көнне гариза бирүчегә КФҮ АМСтан гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы теркәлү номеры һәм гариза бирелгән дата белән расписка бирелә.

22. Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүче Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслый торган, теркәлү номерын һәм гариза биргән датаны күрсәтеп, хәбәрнамә ала.

23. Ике нөсхәдә гариза биргән көнне органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә органның вәкаләтле вазыйфаи заты гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документларны күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә бер нөсхәне кире кайтара.

## Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

23. Хезмәтләр янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

24. Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында җәэмин ителә:

1) инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналардан керү/чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү уңайлылыгы);

2) хезмәт күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән урыннарда урнаштырылган визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе тотрыклы бозылулары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язмаларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Йөртүче этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турындагы" 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән формада һәм тәртиптә бирелгән махсус йөрәтелгәнлеген раслаучы документ булганда йөртүче этне кертү.

26. Регламентның 25 пунктының 1-8 пунктчаларында күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтелә торган объектлардан һәм хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

27. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турындагы мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуын һәм сыйфатын билгеләүче күрсәткечләр

28. Хезмәт күрсәтүнең һәкрем файдалана алырлык булуын билгеләүче күрсәткечләр:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннар булу;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулый торган киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.

29. Хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан регламент бозылуга нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлек саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) гаризаны барлык кирәкле документлар белән тапшырганда мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән үзара эшчәнлеге бер мәртәбә гамәлгә ашырыла;

4.2) хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алырга кирәк булган очракта бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

Хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек итү вакыты 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче хәрәкәтчән радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмалардан файдаланып хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләргә хокуклы.

30. Хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетта яисә Республика порталында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

31. Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮдә аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

32. Мөрәҗәгать итүче хезмәтне комплекслы сорау составында алырга хокуклы.

33. Хезмәт күрсәтүнең сыйфат һәм һәркем файдалана алырлык күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында, КФҮдә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

34. Хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүмат алырга;

б) хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элек 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларның үтәлеше барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

г) хезмәт күрсәтү сыйфатын Республика порталы ярдәмендә бәяләргә;

д) хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

35. Гаризаны формалаштыру гаризаның электрон рәвешен Республика порталында тутыру юлы белән, өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада гариза бирү кирәклегеннән башка гамәлгә ашырыла.

36. КФҮдә кабул итүгә гариза бирүчеләрне язу (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны ярдәмендә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу дата башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Алдан язылып куюны Республика порталы аша башкару өчен мөрәҗәгать итүчегә система соратып алган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләк буенча);

кабул итүнең теләгән көне һәм вакыты.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылганда хәбәр иткән белешмәләр мөрәҗәгать итүченең шәхсән кабул иткәндә тапшырган документларына туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язып куйганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат та, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Алдан язылуны башкарганда мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның билгеләнгән кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, ул килмәгән очракта гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш башка гамәлләр кылуны, кабул итүнең максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

37. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар бүленгән:

а) мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар;

б) мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

39. Гариза формалары һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар турында белешмәләр шушы регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

Административ процедуралар исемлеге

39. Хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

3) ачык тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру, ачык тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен эшкәртү;

4) хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә хезмәт нәтиҗәсен күрсәтү.

## Хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү

40. Хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны теркәү Регламентның 21-23 пунктларында күрсәтелгән вакытта гамәлгә ашырыла.

41. Хезмәт күрсәтү турында гариза һәм Регламентның 3нче кушымтасына китерелгән документлар мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) нигезендә Башкарма комитетка Төбәк порталы аша, КФҮгә тапшырылырга мөмкин.

42. Гаризаны региональ портал аша биргән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр бердәм идентификация һәм аутентификация системасындагы исәп язмасы күрсәтелгән исәп язмасының тиешле күрсәткечләре составыннан расланганда төзелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, гарызнамә җибәрү юлы белән тикшерелергә мөмкин.

Башкарма комитетка, КФҮгә гариза биргән очракта мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтә.

Гарызнамәне мөрәҗәгать итүченең вәкиле биргән очракта вәкил аның вәкаләтләрен раслый торган документның төп нөсхәсен (гарызнамәне Башкарма комитетка, КФҮгә биргәндә) яисә мондый документны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле, шул исәптән нотариуслар (Республика порталы аша гариза биргәндә) тарафиннан “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документның электрон рәвешен күрсәтә.

43. Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризага гади электрон имза белән имза салалар.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә БИАСта теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәп язмасын стандарт дәрәҗәдән түбән булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризага көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имза салалар.

44. Мөрәҗәгать итүче, яшәү урынына яисә тору урынына яисә булу урынына бәйсез рәвештә, хезмәт күрсәтү турында гариза бирергә мөмкин.

## Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

45. Хезмәт күрсәтүне алу өчен “Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмат соратуларын җибәрергә кирәк:

1) “Хокук иясен билгеләү өчен җир кишәрлегенә күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә” җибәрелә.

“Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте” соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

2) “Күчемсез милек объекты турында күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати оратып алу хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә” җибәрелә. “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте” соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

3) “Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу “Федераль салым хезмәтенә” хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. “Федераль салым хезмәте”" сорала торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Гарызнамә хезмәт күрсәтүне сорап юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

4) “Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә” мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу “Федераль салым хезмәтенә” хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. “Федераль салым хезмәте “сорала торган белешмәләрне ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Соратып алу хезмәт күрсәтүне сорап шәхси эшмәкәр мөрәҗәгать иткән очракта башкарыла.

46. Хезмәтне алу өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмат соратып алуларын җибәрергә кирәк:

1) “Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ” соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмат соратып алуы мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, “Гражданлык хәле актларын язуларның Бердәм дәүләт реестры” сервисы йә “Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы” сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

2) “Ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр” соратып алуы. Күрсәтелгән мәгълүмати соратып алу “Нотариатның Бердәм мәгълүмат системасы” сервисы ярдәмендә мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

### Ачык тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру, гавами тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен эшкәртү

47. Ачык тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече тарафыннан, мөрәҗәгать итүче файдалану төрен үзгәртергә теләгән җир кишәрлегенә яисә капиталь төзелеш объектына карата Регламентның 45-46 пунктларында билгеләнгән административ процедура тәмамланганнан соң 22 эш көне дәвамында үткәрелә.

48. Ачык тыңлауларның яисә җәмәгать фикер алышуларының нәтиҗәсе җәмәгать фикер алышуларының яисә ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бастырып чыгарылган бәяләмә, шулай ук хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен кирәкле документлар комплектыннан гыйбарәт.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

49. Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 4 нче кушымтасында каралган нигезләр булган очракта Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече Регламентның 47-48 пунктларында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерли.

50. Регламентның 4 нче кушымтасында каралган хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече Регламентның 47-48 пунктларында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында карар әзерли.

Мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

51. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә Регламентның 49-50 пунктларында билгеләнгән процедураны үтәү тәмамланган көнне күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысулы буларак Республика порталын сайланган очракта хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яисә булу урынына яисә булу урынына бәйсез рәвештә күрсәтелә.

## IV. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү турындагы соратып алуны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

52. Техник мөмкинлек булганда мөрәҗәгать итүчегә Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча соратып алу статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү турында), шулай ук хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче тарафыннан башкарылырга тиешле адымнар һәм гамәлләр, санап үтелгән ысулларның берсе турында хәбәр ителә:

- смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
- Бердәм портал ярдәмендә;
- Республика порталы аша;
- башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

Регламентка
1нче Кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:// www.gosuslugi.ru/ – Бердәм портал;
3. “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Башкарма комитеты (https://arsk.tatarstan.ru/) – Башкарма комитет;
5. “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.

2нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгеләре идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар | Физик зат | 1А |
| 2 | | Юридик зат | 2А |
| 3 | | Шәхси эшмәкәр | 3А |
| 4 | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 4А |

3нче кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларны аныклау, төркемнән документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Шәхесне раслаучы документ | Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 4А | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | Башкарма комитет, Республика порталы, КФҮ |
| *Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга мөмкин булган документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре шәһәр төзелеше регламентына җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен билгеләнгән тәртиптә кертелгәнлеген раслый торган иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар беркетмәсе күчермәсе | Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А-4А | Төзелешкә, реконструкцияләүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын урнаштырганда техник регламентлар таләпләренең үтәлешен раслый торган, үзеннән-үзе җайга салынучы оешмадагы оешма бәяләмәсе рәвешендә шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәтне гамәлгә ашырганда капиталь төзелеш объектлары өчен техник регламентлар таләпләренең үтәлеше турында тапшырыла торган документлар | Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |

4нче кушымта

**Хезмәт күрсәтүдән баш тарту һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен тулы нигезләр**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларны аныклау, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| *Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-4А | рөхсәт аңа карата дәүләт хакимиятенең башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан ирекле төзелешне ачыклау турында хәбәр алынган капиталь төзелеш объекты яисә җир кишәрлеге өчен файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә сорала |
| 2. | 1А-4А | дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарыннан файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә җир кишәрлегенең урнашуы турында мәгълүмат һәм файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән сорала торган төре әлеге зоналар чикләрендәге чикләүләргә каршы килә |
| 3. | 1А-4А | гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек берләшмәсенә бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән аерым бакча яисә яшелчә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү |
| 4. | 1А-4А | файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүдән баш тарту турында, шул исәптән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча тискәре бәяләмәне исәпкә алып, комиссия тәкъдимнәре |
| 5. | 1А-4А | файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә сорала торган рөхсәт техник регламентлар, шәһәр төзелеше, төзелеш, санитар-эпидемиологик, янгынга каршы һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нормалар һәм кагыйдәләр таләпләрен бозуга китерә |
| 6. | 1А-4А | мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча хезмәт күрсәтүгә гаризаның кире алынуы |
| *Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-4А | Регламентның 3 нче кушымтасында билгеләнгән документларны тапшырмау |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1А-4А | ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турындагы белешмәләрне расламау, гаризаның (гарызнамәнең) мөрәҗәгать итүче исеменнән аны бирүгә вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан бирелүе |
| 3. | 1А-4А | документларны тиешсез органга тапшыру |
| 4. | 1А-4А | дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр, килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген берсүзсез аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар булган документларны, үз көчен югалткан документларны тапшыру |
| 5. | 1А-4А | муниципаль хезмәтне Регламент нигезендә муниципаль хезмәтне алучы булып тормаган заттан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү |
| 6. | 1А-4А | гаризаның электрон рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон рәвешендә һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу |
| 7. | 1А-4А | гаризада һәм аңа кушып бирелгән документларда каршылыклы белешмәләр булу |
| 8. | 1А-4А | мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда текстны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар һәм төзәтүләр булуы |

5нче кушымта
(якынча форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Җир кишәрлегеннән (капиталь төзелеш объектыннан) файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы ____________ муниөипаль районы Советы ның “___” ___________ ел, ____ номерлы карары белән расланган җирдән файдалану һәм ____________ муниципаль берәмлеген төзү кагыйдәләре, Росреестрның “Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында” 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән, ___________________ Башлыгының “Ачык тыңлаулар уздыру турында” “__” _______________ ел, _____ номерлы карары нигезендә үткәрелгән “___” _____________ ел, ______ номерлы ачык тыңлаулар (“________________” газетасында “__” _______________ел, №_______ белдерү) нәтиҗәләре буенча берткетмә, нәтиҗә нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. “___________________________________”, җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча код № ________ - “_______________________” кадастр номерлы җир кишәрлегенә (капиталь төзелеш объектына) карата_________________________________________, ________________________________________________________________________адресы буенча урнашкан җир кишәрлегеннән (капиталь төзелеш объектыннан) файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына (ФИО) әлеге карарны “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына җибәрергә (җир-кадастр документациясенә тиешле үзгәрешләр кертү өчен).

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә әлеге карарны “___________________” гас\зетасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны ___________________________________ йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе имза ФИО

6нчы кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

## Хәбәрнамә

Мөрәҗәгате нигезендә ___________________________________________________
(Физик затның Ф.И.О, юридик затның исеме – мөрәҗәгать итүче)

гариза № _______ _____._____.________ел, __________________________________________

__________________________________________________________________турында

нигезендә: ____________________________________________________________

_____________________________________________________________________,

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында тбәндәге нәтиҗәләр буенча карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфаи зат (ФИО) ______________________________

(килештерүне башкаручы органның вазыйфаи затының имзасы)

Башкаручы (ФИО)

______________________________

(башкаручының контактлары)

7нче кушымта

__________________________________________
(муниципаль берәмлекнең
_________________________________________гә
җирле үзидарә органы исеме)
__________________________________________
__________________________дән ( алга таба – мөрәҗәгать итүче).
(юридик затлар өчен – тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, дәүләт теркәве турында белешмәләр, урнашу урыны, контакт мәгълүматы;
физик затлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефоны)

Гариза
җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

______________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

*Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре, җир кишәрлеге турында белешмәләр: адресы, кадастр номеры, мәйданы, рөхсәт ителгән файдалану төре, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы реквизитлары; капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре, капиталь төзелеш объекты турында белешмәләр: кадастр номеры, мәйданы, катлары, билгеләнеше)*
*Урнаштыруга планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларына характеристика*

җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мөмкинлеген каравыгызны сорыйм

Урнаштыруга планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларына характеристика
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән сорала торган төрен нигезләү
__________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен җибәрүегезне сорыйм:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы

шәхси кабинетка;

КФҮдә;

органда

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | _________________ ( | ________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.О.) |

8нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Хәбәрнамә

Мөрәҗәгате нигезендә_______________________________________________

(Физик затның Ф.И.О, юридик затның исеме – мөрәҗәгать итүче)

гариза № _______ _____._____.________ел, ________________________________

_______________________________________________________________турында

нигезендә: ______________________________________________________

_______________________________________________________________,

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча документларны кабул итүдән баш тарту турында тбәндәге нәтиҗәләр буенча карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфаи зат (ФИО) ______________________________

(килештерүне башкаручы органның вазыйфаи затының имзасы)

Башкаручы (ФИО)

______________________________

(башкаручының контактлары)

9нчы кушымта

Татарстан Республикасы
______________________________
муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә

____________________________**дән**

**Техник хатаны төзәтү турында**
**Гариза**

Хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________________________

(хезмәт исеме)

Язылды:____________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:__________________________________________________
______________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегезне һәм Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон дкументны E-mail адресына җибәрү юлы белән:_______;

почта юлламасы белән кәгазь чыганактагы таныкланган күчермә рәвешендә: ________________________________________________________________.

Шушы мәгълүмат белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм тапшырылучы затка кагылышлы, шулай ук мин түбәндә кerткән мәгълүматлар дөрес. Гаризага беркетелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшыру вакытына әлеге документлар дөрес һәм дөрес белешмәләр үз эченә ала.

______________ _________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.)